КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2020 ел, 25 июль г.Казань № б-1409

1. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының «Клиентлаштырылган цифрлы хезмәтләр күрсәтүнең бүленгән архитектурасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы эшләвен тәэмин итү өчен кирәкле техник чараларда урнашкан әлеге системаны эшкәртүгә (модификацияләүгә) концессия килешүе төзү хокукына ачык конкурс үткәрү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Бу боерыкка теркәлгән «Клиентлаштырылган цифрлы хезмәтләр күрсәтүнең бүленгән архитектурасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы эшләвен тәэмин итү өчен кирәкле техник чараларда урнашкан әлеге системаны эшкәртүгә (модификацияләүгә) концессия килешүенең төп шартларын, конкурс критерийларын һәм конкурс критерийларының параметрларын расларга.

3. Концедент вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы гамәлгә ашыра дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына 30 көн эчендә:

бу боерыкның 1 нче пунктында күрсәтелгән объектка карата концессия килешүе төзү хокукына конкурс үткәрү буенча конкурс документларын билгеләнгән тәртиптә расларга;

ачык конкурс үткәрү турындагы хәбәрләрне Татарстан Республикасының рәсми матбугат басмасында бастырып чыгарырга, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта урнаштыруны гамәлгә ашырырга;

конкурс үткәрү буенча конкурс комиссиясе төзергә һәм аның составын расларга;

концессия килешүе төзү турында карар кабул итәргә.

5. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин